**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 20 апрелендәге 1293 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2015 елның 6 февралендәге 522 номерлы карары белән расланган «Юдино» районы территориясен планлаштыру проектына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 42, 45 һәм 46 статьяларына таянып, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 2 февралендәге 112 номерлы «Федераль башкарма хакимиятнең вәкаләтле органнары, вәкаләтле Россия Федерациясе субъектларының башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнары карарлары нигезендә әзерләнә торган территорияне планлаштыру документларын әзерләү, территорияне планлаштыру документларын раслау турында карар кабул итү, мондый документларга үзгәрешләр кертү, мондый документларны яки аның аерым өлешләрен гамәлдән чыгару, мондый документларның аерым өлешләрен кулланылырга тиеш түгел дип тану, шулай ук федераль һәм төбәк әһәмиятендәге тарихи җирлекләр территорияләренә карата территорияне планлаштыру проектын әзерләү һәм раслау кагыйдәләрен раслау турында»гы карары нигезендә **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2015 елның 6 февралендәге 522 номерлы карары белән расланган «Юдино» районы территориясен планлаштыру проектына (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 19 сентябрендәге 3134 номерлы, 2022 елның 8 декабрендәге 4276 номерлы, 2023 елның 6 октябрендәге 3022 номерлы, 2024 елның 8 февралендәге 431 номерлы, 2024 елның 13 сентябрендәге 3891 номерлы, 2025 елның 7 мартындагы 614 номерлы, 2025 елның 29 апрелендәге 1320 номерлы һәм 2025 елның 17 июлендәге 2235 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), әлеге карар кушымтасы нигезендә планлаштыру проектының аерым өлешләрен раслау юлы белән үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары А.Р.Нигъмәтҗановка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре Башкарма
комитетының 2026 елның
20 апрелендәге 1293 номерлы
карарына кушымта

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2015 елның 6 февралендәге 522 номерлы карары белән расланган «Юдино» районы территориясен планлаштыру проектына кертелә торган үзгәрешләр**

1. «Җирле әһәмияттәге капиталь төзелеш объектларын урнаштыру, шулай ук территорияне план буенча үстерү характеристикалары һәм «Юдино» районы территориясен үстерү өчен кирәкле социаль, транспорт хезмәте күрсәтү системаларын үстерү һәм инженерлык-техник яктан тәэмин итү характеристикалары турындагы нигезләмә»нең I бүлегендә «Территорияне шәһәр төзелеше нигезендә зоналаштыру, территорияне төзү параметрлары, Займище һәм Күзәмәт торак массивлары арасындагы капиталь төзелеш объектларына характеристикалар» таблицасына түбәндәге эчтәлекле юллар өстәргә:

| **Территорияне планлаштыру сызымында зона номеры** | **Капиталь төзелеш объектларын урнаштыру зонасы төре** | **Урнаштыру зонасы мәйданы, га** | **Капиталь төзелеш объектларында катларның максималь саны** | **Торак фондының максималь гомуми мәйданы, мең кв. м** | **Торак фондының максималь тыгызлыгы мең кв. м/га** | **Халык саны, кеше** | **Йорт эченә кертеп-кушып төзелгән җәмәгать билгеләнешендәге биналарның гомуми мәйданы, мең кв.м** | **Торак йортлар төзү мәйданы** | **Рөхсәт ителгән файдалану төрләре кодлары** | **Урнаштырыла торган объектлар турында белешмәләр** |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «27 | Күпкатлы торак төзелешен урнаштыру зонасы | 1,06 | билгеләнмәгән | билгеләнмәгән | билгеләнмәгән | билгеләнмәгән | билгеләнмәгән | билгеләнмәгән | 2.5, 2.6, 2.7.1, 3.1.1, 3.2.2, 3.2.3, 3.3, 3.4.1, 3.4.2, 3.5.1, 3.6.1, 3.8.1, 4.4, 4.5, 4.6, 4.9.2, 5.1.2, 5.1.3, 8.3 | Контроль-үткәрү пункты, склад, түбәле корылма |
| 28 | Транспорт инфраструктурасын урнаштыру зонасы | 1,05 | билгеләнмәгән | билгеләнмәгән | 0 | 0 | билгеләнмәгән | 0 | 4.1, 4.9, 4.9.1, 4.9.2, 5.1.4 | Административ бина, түбәле корылма» |

2. Кызыл линияләрне, социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объектларны, җирле әһәмияттәге капиталь төзелеш объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләре күрсәтелгән планлаштыру проекты сызымының шартлы билгеләрендә:

2.1. күпкатлы торак төзелешен урнаштыру зонасының тәртип номерында «билгеләнмәгән» тамгасын «27» санына алмаштырырга;

2.2. транспорт инфраструктурасын урнаштыру зонасының тәртип номерында «билгеләнмәгән» тамгасын «28» санына алмаштырырга;

2.3. транспорт инфраструктурасын урнаштыру зонасының «4.9, 4.9.1, 4.9.2, 5.1.4» саннары исемлегенә «4.1» саннарын өстәргә.